ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2019 Казан шәһәре № 5-49/тэ

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2018 № 5-8/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2020-2023 елларга көйләнүче оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларга 2020-2023 еллар өчен үзгәрешләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 16.11.2018 № 5-8/тэ номерлы карарына 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2018 № 5-8/тэ карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 27.11.2019
№ 5-49/тэ карары редакциясендә)

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 65,35 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 66,75 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 66,75 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 66,77 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 66,77 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 68,59 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 68,16 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 69,01 | - |
| | | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 69,01 | - |
| | | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 70,23 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге